ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
III чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
III созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

КАРАР
от 28.04.2020г

РЕШЕНИЕ
№46-02

Актаныш муниципаль районында эпидемиологик хәл һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын таралуны булдырмау чаралары турында

Яр Чаллы шәһәрендә, Актаныш, Тукай, Мәслим, Минзәлә районнарында (Чаллы ТО) кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт Идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы урынбасары Л.М.Хафизованың Актаныш муниципаль районында эпидемиологик хәл һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын таралуны булдырмау чаралары турында докладын тыңлаганнан соң, Актаныш муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсенең Чаллы шәһәре, Актаныш, Тукай, Мәслим, Минзәлә районнары (Чаллы ТО) буенча территориаль бүлеге башлыгы урынбасары Л.М.Хафизова мәгълүматын Актаныш муниципаль районында яңа коронавирус йогышлы авыруын таралуны булдырмау чаралары турында игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).

2. Барлык предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә, Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлекләрендә әлеге карарга таянып эш итәргә, куелган бурычларны тормышка ашыруда һәм әлеге карарның үтәлешен тәэмин итүдә актив катнашырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы башлыгы урынбасары Р.Ф.Галимҗановага йөкләргә.

Актаныш муниципаль район
Советы рәисе

Э.Н.Фәттахов